КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 23 август г.Казань № 689

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә эшләнә торган әйберләрне халык сәнгать һөнәрләре әйберләренә кертү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 26 декабрь, 1038 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә эшләнә торган әйберләрне халык сәнгать һөнәрләре әйберләренә кертү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 26 декабрь, 1038 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «Халык сәнгать һөнәрләре һәм кәсепләре турында» 2005 елның 12 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын» сүзләрен «Халык сәнгать һөнәрләре турында» 2024 елның 18 июнендәге 46-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә эшләнә торган әйберләрне халык сәнгать һөнәрләре әйберләренә кертү тәртибенә түбәндәге эчтәлекле 2.2 пункт өстәргә:

«2.2. Советның әйберләрне халык сәнгать һөнәрләре әйберләренә кертү мәсьәләләре буенча кабул ителә торган карарлары Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәркем файдалана торган итеп (мондый карарларда булган һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә файдалану мөмкинлеге чикләнгән белешмәләрдән тыш) урнаштырыла.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин